ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/8

Товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2019 елның 01 маендагы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»71-ФЗ санлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе 2 өлеше һәм 69 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2014 елның 09 декабрендәге 35/8 санлы Карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/9, 2016 елның 24 февралендәге 6/7, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/8, 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/8 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктның 8 пунктчасында «сатып алу планнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7 пунктта:

- 1 пунктчада «сатып алу планнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 4 пунктчада «вәкаләтле органга (электрон формада яки кәгазьдә)» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү буенча хокук куллану функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органына (Федераль казначылыкка)» сүзләренә алыштырырга;

3) 10 пунктта «сатып алу планнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 12 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«12. Сатып алуларны планлаштыру план-графикларны формалаштыру, раслау һәм алып бару юлы белән тормышка ашырыла. План-графикларда каралмаган сатып алулар тормышка ашырыла алмый.

План-графиклар Шәһәр Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджеты турында карарының гамәли чорына туры килә торган вакытка төзелә. План-графикка, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезләмәләрен исәпкә алып, гамәлгә ашыру план чорыннан соң планлаштырылган сатып алулар турында мәгълүмат кертелә. Бу очракта мәгълүмат планлаштырылган сатып алуларның тулы сроклы алу план-графикларына кертелә,»;

5) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. План-график, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезләмәләрен исәпкә алып, шәһәр бюджеты проектын төзү һәм карау процессында муниципаль заказчы тарафыннан төзелә һәм Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, йөкләмәләрне кабул итүгә һәм (яисә) үтәүгә хокукларның акчалата күләмен муниципаль заказчыга җиткергәннән соң ун эш көне эчендә расланa.

План-график муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан муниципаль учреждениеләрнең, муниципаль унитар предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда төзелә һәм муниципаль учреждениеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын, муниципаль унитар предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын (программасын) раслаганнан соң ун көн эчендә расланa.

Заказчы тарафыннан расланган план-график һәм аңа кертелгән үзгәрешләр, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән тыш, план-графикны раслау яисә үзгәртү датасыннан алып өч эш көне эчендә, бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

6) 14 пунктта «План-графикларда каралмаган сатып алулар гамәлгә ашырылырга тиеш түгел.» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Зарурлыктан чыгып, план-графиклар үзгәртелә:

1) аларны законның 19 маддәсе нигезендә заказчылар тарафыннан сатып алына торган товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләрен) һәм (яки) муниципаль органнар функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны үзгәртүгә бәйле рәвештә үзгәртү кирәк булганда;

2) аларны Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә йөкләмәләрне кабул итүгә һәм (яки) үтәүгә заказчыга җиткерелгән хокук күләмен үзгәртүгә, муниципаль учреждениеләрнең, муниципаль

унитар предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары (программалары) күрсәткечләрен үзгәртүгә, тиешле карарларны һәм (яисә) субсидияләр бирү турындагы килешүләрне үзгәртүгә бәйле рәвештә үзгәртү кирәк булганда

3) Федераль законның 20 маддәсе нигезендә сатып алулар буенча мәҗбүри иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча заказчы тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашырганда;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә сатып алуларны тормышка ашырганда алынган экономияне кулланганда;

5) башка очракларда, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән план-графикларны формалаштыру, раслау, үзгәрешләр кертү тәртибе нигезендә.

План-графикка үзгәрешләр кертү тиешле сатып алуларны гамәлгә ашыру турында хәбәр итүнең бердәм мәгълүмат системасында урнашасы көнгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча яисә ябык ысул белән тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) оешманы билгеләүдә катнашырга чакыру җибәрүне яисә бердәнбер тәэминатчы (подрядчы, башкаручы) белән контракт төзегән очракта, Федераль законның 93 маддәсе 1 өлеше нигезендә - контракт төзелгән көнгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

8) 18 пунктны көчен югалткан дип танырга;

9) 19 пунктта «һәм» сүзеннән соң «сатып алулар планы» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 20 пунктның 3 пунктчасында «сатып алулар планы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев